**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның «19» октябреннән № 238

2024 елда Татарстан Ресаубликасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында

Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, укучыларны балансланган кайнар туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, 2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7 өлеше, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024-2026 елларга айлык акчалата һәм башка түләүләр турында» 2023 елның 07 сентябрендәге 1099 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча белем алучы укучыларга түләүсез кайнар туклану оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм кайнар туклануның уртача бәясен раслау турында» 2023 елның 04 сентябрендәге 1066 номерлы карары, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елның 01 октябреннән алып Яңа Чишмә муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» 2020 елның 12 октябрендәге 257 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының аз тәэмин ителгән гаиләләреннән белем алучыларны бушлай тукландыруны тәэмин итү тәртибе турында нигезләмә нигезендә, Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

1.1 Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының 1-4 класс укучыларын уртача бәясе 66,76 сумлык кайнар тукландыру оештырырга;

1.2 Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының 5-11 сыйныф укучыларын һәр уку көненә 9 сум 20 тиен күләмендә субсидиядән һәм ата-аналар түләвеннән торган суммага кайнар тукландыруны оештырырга;

1.3 гаиләнең бер әгъзасына туры килгән Татарстан Республикасы буенча 40 сум күләмендә билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган аз керемле гаиләләрдән булган укучылар өчен бсубсидияне исәпкә алып, җирле бюджет акчалары исәбеннән бушлай кайнар иртәнге ашлар оештырырга;

1.4. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән (ОВЗ) укучыларны җирле бюджет акчалары хисабына, шул исәптән субсидияләрне дә кертеп, ике тапкыр бушлай ашатуны оештырырга:

1-4 сыйныфлар өчен бәясе 66,76 сумлык һәм 40 сумлык;

5-11 сыйныфлар өчен бәясе 9,2 сумлык һәм 40 сумлык.

1.5. Ата-аналары яки законлы вәкилләре махсус хәрби операциядә катнашу өчен мобилизацияләнгән гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары өчен бушлай 2 тапкыр туклану оештырырга:

1-4 сыйныфлар өчен бәясе 66,76 сумлык һәм 40 сумлык;

5-11 сыйныфлар өчен бәясе 9,2 сумлык һәм 40 сумлык.

1.6. 5 көн эчендә бушлай тукландыру өчен 1.2 пунктта күрсәтелгән категорияләргә кергән укучылар исемлеген бирергә.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына мәгариф учреждениеләре киселешендә аз керемле гаиләләрдән булган балаларны бушлай тукландыруны оештыру чыгымнарын Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты хисабына финанслауны башкарырга.

3. Мәктәп укучыларын кайнар аш белән тәэмин итүче гомуми белем бирү учреждениеләре һәм башка предприятиеләр җитәкчеләренә:

3.1. Мәктәп ашханәләрен сыйфатлы азык-төлек белән өзлексез тәэмин итәргә.

3.2. Витаминнар, микронутриентлар белән баетылган төп туклыклы матдәләрне карап тоту буенча балансланган иртәнге һәм төшке ашларның нормаларын һәм сыйфатын исәпкә алуны һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

3.3. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыруны, санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм «гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучылар туклануын оештыруга санитария-эпидемиология таләпләре» СанПин 2.4.5.2409-08 нормативлары нигезендә, «Санитар кагыйдәләрне үтәү һәм санитария-эпидемияләргә каршы (профилактика) чаралар үтәүгә производство контролен оештыру һәм үткәрү» СП 1.1.1058-01 номерлы СанПиН нигезендә производство контролен башкарырга.

4. Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларына түләүсез тукlануны оештыру буенча социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан һәм, билгеләгән форматларга туры китереп, Социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы операторы аша алынырга мөмкин».

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http//novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

7. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы белем

бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2022елның 23 декабрендәге 372 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов